ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» август 2020 ел № 235

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районында рационализаторлык эшчәнлеге турында

«Ачышлар, уйлап табулар һәм рационализаторлык тәкъдимнәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» СССР Министрлар Советының 1973 елның 21 августындагы 584 номерлы карары, «Татарстан Республикасында уйлап табулардан һәм рационализаторлык тәкъдимнәреннән файдалануның еллык икътисадый нәтиҗәсен билгеләү нигезләмәсен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 26 гыйнварындагы 36 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2011 елның 11 декабрендәге 2084-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык эшчәнлеген үстерүне стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык эшчәнлеге турында нигезләмә;

1.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү комиссиясе составы.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Р.Вәлиев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.08.2020 ел, № 235
карары белән расланган

# Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык эшчәнлеге турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Әгерҗе муниципаль районы гражданнарының тормыш сыйфатын күтәрү, инвестиция эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру, бюджет процессын камилләштерү, район буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук Әгерҗе муниципаль районында эшли торган милек рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятиеләр (оешмалар, учреждениеләр) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында эшләнде.

## II. Рационализаторлык эшчәнлегендә катнашучылар

2.1. Рационализация эшчәнлегендә катнашучылар дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гражданнары;
- җирле үзидарә органнары һәм аңа буйсынучы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре;
- милек рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятиеләр (оешмалар, учреждениеләр) җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре.

## III. Рационализаторлык тәкъдимнәрен бирү тәртибе

3.1. Рационализация эшчәнлегендә катнашучылар Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү комиссиясенә (алга таба - Комиссия) тәкъдимнәр кертәләр.

3.2. Кертелгән тәкъдимнәр рационализаторлык эшчәнлегендә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр булганда, комиссия утырышында айга бер тапкыр планлы тәртиптә карала.

3.3. Рационализаторлык тәкъдимнәрен тану өчен катнашучылар рационализаторлык тәкъдиме турында Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә язмача гариза бирәләр (1 нче кушымта).

3.4. Гаризага тәкъдимнәрне бәяләү өчен хисаплар, сызымнар, схемалар, эскизлар, таблицалар һәм башка материаллар өстәлә.

Рационализаторлык тәкъдиме турында гариза һәм аңа кушымта итеп бирелә торган материаллар, төзү датасын күрсәтеп, катнашучы тарафыннан шәхсән имзаланырга тиеш.

Әлеге Нигезләмә таләпләрен бозып төзелгән тәкъдимнәрне бәяләү өчен материаллар кушымтасы белән гариза карауга алынмый һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылырга тиеш.

3.5. Кабул ителгән гариза Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетында кергән көнне теркәлә. Гаризада тәкъдим бирү датасы һәм кабул итү

турында беркетелгән теркәү номеры куела.

3.6. Рационализаторлык тәкъдиме турында карар чыгарганчы катнашучы аңа тәкъдимнәрнең асылын үзгәртми торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертә. Үзгәрешләр һәм өстәмәләр, катнашучы биргән һәм аңа кул куйган датаны күрсәтеп, аерым биттә рәсмиләштерелергә тиеш.

3.7. Рационализаторлык тәкъдиме турында башта теркәлгән гаризаның асылын үзгәртү яңа тәкъдим буларак карала, аңа яңа гариза тапшырылырга тиеш.

3.8. Гариза кергәннән яки аңа соңгы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгәннән соң 30 көн эчендә карала.

3.9. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карар кабул иткәндә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының «хуплап» һәм «каршы» бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, комиссия рәисе (утырышта рәислек итүче) тавышы хәлиткеч була.

Көн тәртибе мәсьәләләре буенча комиссия карарлары комиссиянең шунда катнашучы хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия карары белән килешмәгән комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары комиссия беркетмәсендә чагылдырыла торган һәм шушы фикерне бәян иткән карарга кушып бирелә торган аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

3.10. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Комиссия беркетмәсенә комиссия рәисе һәм секретаре (утырышта рәислек итүче һәм утырыш секретаре) имза сала.

Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- утырышны уздыру урыны һәм вакыты;
- көн тәртибендәге мәсьәләләр;
- утырышларда катнашучылар составы;
- утырышларда катнашучыларның чыгышларының төп нигезләмәләре;
- тавыш бирүгә куелган сораулар һәм алар буенча тавыш бирү йомгаклары;
- тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар.

## IV. Рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү

4.1. Рационализация тәкъдимнәрен бәяләгәндә, аларны гамәли тормышка ашыруга (финанс, матди, хезмәт һәм башка ресурслар), шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге, инвестицияләрнең үз-үзен аклау вакыты исәпкә алына.

Социаль-икътисадый нәтиҗә дигәндә болар аңлашыла:

- Әгерже муниципаль районы гражданнарының тормыш сыйфатын күтәрү;
-Әгерже муниципаль районының берләштерелгән бюджеты керемнәрен арттыру;
- Әгерже муниципаль районының берләштерелгән бюджетын тотуны экономияләү;
- муниципаль функцияләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру;
- Әгерже муниципаль районында хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын һәм аның һәркем өчен ачык булуын арттыру;
- Әгерже муниципаль районының инвестицион җәлеп итүчәнлеген яхшырту;
- милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятиеләр (оешмалар, учреждениеләр) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

4.2. Кергән рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү нәтиҗәләре буенча, комиссиянең уңай карары булган очракта, тәкъдимнәр тиешле предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә карау өчен җибәрелә.

4.3. Катнашучыларның рационализаторлык тәкъдимнәрен, шул исәптән хезмәт килешүе, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре һәм гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка кабул ителгән норматив документлар белән билгеләнгән рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү нәтиҗәләре буенча бүләкләүнең матди һәм матди булмаган формалары:

4.3.1. Матди кызыксындыру формалары:

- муниципаль учреждение хезмәткәре, җирле үзидарә органы һәм ведомство буйсынуындагы учреждение хезмәткәренең хезмәт хакына бер мәртәбә түләнә торган премия;

- законнар таләпләре нигезендә башка бүләкләүләр.

4.3.2. Матди булмаган кызыксындыру формалары:

- рационализаторлык эшчәнлеге турында мәгълүмат стендларында, массакүләм мәгълүмат чараларында, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру;

- Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесеннән районны яхшыртуда катнашкан һәм нәтиҗәләргә ирешкән өчен рәхмәт белдерү;

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы һәм рәхмәт хаты турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 48-4 номерлы карары нигезендә Әгерҗе муниципаль районы башлыгынын мактау грамотасы, рәхмәт хаты белән бүләкләү;

- вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм, «Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәнең яңа редакциясендә раслау хакында» 2017 елның 26 апрелендәге 18-9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары нигезендә, Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервына кертү,

- законнар таләпләре нигезендә башка бүләкләүләр.

4.4. Рационализация тәкъдимнәрен бәяләгәндә, катнашучы кадрлар резервына кертү өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районын җирле үзидарә органнарына тәкъдим ителергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районында
рационализаторлык эшчәнлеге турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан
Республикасы
Әгерҗе муниципаль
районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенә

___________________________

**Рационализатор тәкъдиме турында гариза**

**ТӘКЪДИМ ИСЕМЕ:**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**ИСӘПЛӘНГӘН КЕРТҮ УРЫНЫ:**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(тармак, оешма һ. б..)

**ТӘКЪДИМНЕҢ ТАСВИРЛАМАСЫ:**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**КӨТЕЛГӘН СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ НӘТИҖӘ:**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**ТӘКЪДИМНӘР КЕРТҮ ӨЧЕН ЧЫГЫМНАР:**

**КУШЫМТА (документ атамасы, битләр саны, экз.):**

| | |
|---|---|
| 1. | |
| 2. | |
| 3. | |
| … | |

(вазыйфа, имза, ФИО)

«______»_____________ 20____ ел.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.08.2020 ел, № 235
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында рационализаторлык тәкъдимнәрен бәяләү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | **Комиссия рәисе**,<br>Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | **Вәлиев Азат Рөстәмович** |
| 2. | **Комиссия рәисе урынбасары**,<br>Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | **Баженова Ольга Алексеевна** |
| 3. | **Комиссия секретаре**,<br>Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе | **Рыкова Энже Рафисовна** |
| | **Комиссия әгъзалары:** | |
| 4. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килештерү буенча) | **Закирова Резида Әмировна** |
| 5. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл жирлеге җитәкчесе (килештерү буенча) | **Нуриев Зөлфәт Равилович** |
| 6. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе (килештерү буенча) | **Хәбирова Алия Шамилевна** |
| 7. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | **Гыйльметдинова Римма Ринатовна** |
| 8. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | **Шамсетдинов Илшат Илдусович** |
| 9. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты житәкчесе (килештерү буенча) | **Рәхмәтулин Әнвәр Мянсурович** |
| 10. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) | **Бадахшин Альфред Нәвитович** |
| 11. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Олимп» спорт-савыктыру комплексы» МБУ директоры (килештерү буенча) | **Гобәйдуллин Рөстәм Рәзилевич** |
| 12. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын юридик бүлеге начальнигы | **Фатхетдинова Ләйсән Газинуровна** |
| 13. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлеге начальнигы | **Хәкимова Надежда Минзаһитовна** |
| 14. | «Татмедиа» ААҖ филиалы директоры «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясе директоры (килештерү буенча) | **Абзалиева Дания Зәнгировна** |